
**Кем ераграк ыргыта?**

Уйнаучылар 2 яки 3 рәткә тезеләләр. Мәйданның киңлегенә карап, һәрбер рәђттә 7–8 кеше була. Беренче рәттә басып торучыларның кулларында туп. Алар, тәрбиячененң «Башлагыз!» дигән сигналына карап, кулларындагы тупларын ыргыталар. Ераграк ыргыткан бала мактала. Тупны ыргыткан балалар туплары артыннан йөгереп баралар да аны артларында торучыларга бирәләр.

**Куяннар һәм аучылар**

Санамыш ярдәмендәике бала «аучы» итеп билгеләнә. Калган балалар «куяннар» булалар. Аучылар мәйданчык-ның төрле урыннарында таралып йөриләр. Куяннар мәй-данчык буйлап йөгерешәләр, сикерәләр. Тәрбияченең «Аучылар!» дип әйтүенә, куяннар теләсә нинди торышта катып калалар һәм шул килеш селкенмичә торалар. Аучылар туктап калган урыннарыннан куяннарга аталар – аларга кар йомарламнары ыргыталар. Аучы кемгә кар-ны тидерсә, шуны, үзе белән алып китеп, билгеле бер урынга (читлеккә) утырта. Уен 2–3 тапкыр кабатланган-нан соң, һәр аучының ничә куян атканлыгы санала. Ан-нан соң, яңа «аучылар» сайланып, уен яңадан кабатлана.

***Бергәләп өйрәник***



***Куркынычсызлык кагыйдәләре***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

## Мәкальләр

*Аюдан курыксаң, урманга барма,

*Бүредән курыксаң, сарык асрама.

* Ике куянны берьюлы кумыйлар.

* Юлда йөрергә дә акыл кирәк.

* Урау булса да, юл яхшы.

* Юлга чыксаң, азыгың үзең белән булсын. (Йозак)

**Табышмаклар**

* Авызы юк, борыны юк,

Тик бар аның өч күзе.

Урамдагы хәрәкәтне

Көйләп торадыр үзе.

(Светофор)

* Башыбыз бар, гәүдәбез бар,

Юк кул, аякларыбыз.

Балалар тотса куркабыз —

Яман шул якларыбыз.

(Шырпы)

* Пожар турында ишеткәч,

Сигнал бирергә ашык.

Янгын гел көчәя бара,

Туктатып булмый ич һич.

Су гына сүндермәс аны,

Кирәк шул... (ут сүндергеч).

* Автомобиль, трамвайдан

Саклан, димен, бик сак бул!

Уйный торган урын түгел

Машиналар йөргән... (юл).

**Батыр кызчык**

Күрче, әнә бер кызчык

Ә кызчык бер курыкмый,

Песиен ничек тоткан

Тып итеп аяк тибә,

Маэмай аңа тимәсен,

Бармак яный маэмайга:

Яклаучысыз димәсен.

Син минем дуска тимә!

Һау-һаулап маэмай өрә,

Бигрәк тә нәни кызчык,

Уенда ни — кем белә?..

Ә үзе батыр ничек!

Йә эләктереп алса?

Яздым әле шул хакта,

Йә селтәп җиргә салса?

Улым, дим, син дә ишет.

*Бикә Рәхимова*